РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
« 06» май 2021 ел

КАРАР
№26

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле
әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешенә һәм 14 статьясындагы 1 өлешнең 20 пунктына кергән үзгәрешләр, ТР Сарман муниципаль районы Советының «шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында» 19.04.2021 номерлы карары, Александровка авыл җирлеге советының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында" карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " муниципаль берәмлегенең түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:
- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм раслау;
- җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау һәм үзгәрешләр кертү.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар бер елга билгеләнә һәм ул басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге
Советы Рәисе

А.Р.Гафиятуллин